КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1005

Кайбер дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәт-кәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабине-тының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура

һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 7 август, 660 нчы; 2020 ел, 27 август, 748 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы; 2022 ел, 22 август, 880 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бу карарның 1 пункты нигезендә учреждениеләр җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белгеченең вазифаи оклады күләмен 1,061 тапкырга индексларга һәм аны 12 688 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1287 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы; 2022 ел, 2 август, 751 нче; 2022 ел, 22 август, 878 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «ике проценты» сүзләрен «15 проценты» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 6 пунктчасындагы өченче абзацында «сәгатьле тариф ставкасының 7 проценты күләмендә» сүзләрен «хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән күләмдә» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның 4 пунктчасында «ике проценты» сүзләрен «15 проценты» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Учреждениеләр җитәкчеләренә элегрәк чыгарылган актларын бу карарга туры китерергә.

6. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин